**КАРАР**

**26 ноябрь 2020 ел** **№1**

**Кукмара муниципаль районы Түбән Үрәс авыл җирлегенең Танькино авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2020 елның 26 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча үткәрелгән гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенының беркетмәсе төзелде:

«Көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, 80 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк яшьтәге затлардан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Түбән Үрәс авыл җирлегенең Танькино авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2021 елда үзара салымны 700 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- Танькино авылы юлларындагы чокырларны төзекләндерү (ямочный ремонт); проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;

- урам утлары (электр товарларны сатып алу);

- су башнясы өчен насос сатып алу?.

«РИЗА” «КАРШЫ»”

Гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 33 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 22 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Риза» позициясе өчен җыенда катнашкан 22 кеше тавыш бирде;

«Каршы» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде;

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Түбән Үрәс авыл җирлегенең Танькино авылында халык җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип таныерга.

2. Түбәндәге мәсьәлә буенча карарны: «Көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, 80 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк яшьтәге затлардан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Түбән Үрәс авыл җирлегенең Танькино авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2021 елда үзара салымны 700 сум күләмендә

кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- Таңкино авылы юлларындагы чокырларны төзекләндерү (ямочный ремонт); проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;
- урам утлары (электр товарларны сатып алу);
- су башнясы өчен насос сатып алу?.

«РИЗА» «КАРШЫ»

кабул ителгән дип таныырга.

3. Җыенның нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Түбән Үрәс
авыл җирлеге башлыгы Р.Х.Шамеев